ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы
Александровка авыл җирлегенең Татар Карамалысы торак пунктында
2025 елда үзара салым кертү турында

16 ноябрь 2024 ел № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында " 2003 елнын 06 октябрендәгы № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Александровка авыл җирлегенең Татар Карамалысы авылында гражданнар җыены

КАРАР БИРДЕ:

1. 2025 елда Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Александровка авыл җирлеге Татар Карамалысы авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булмаган, инвалидлардан, яшәүче олкэннэр (80 яшькә җиткән), көндезге формада белем алучы студентлардан, ашыгыч хәрби хезмәт, контракт буенча хәрби хезмәт, мобилизация буенча хәрби хезмәт узучылардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрергә:

1) Татар Карамалысы авылы урамнарында яктырту челтәрләрен ремонтлау, урамнарны яктырту җайланмасы (лампаларны, энергияне сак тотучы яктырткычларны, электр товарларын сатып алу һәм урнаштыру, урам яктырткычларын агымдагы ремонтлау һәм аларга хезмәт күрсәтү);
2) Татар Карамалы авылы зиратын киртәләү өчен төзелеш материаллары сатып алу;
3) Татар Карамалы торак пунктларында гомуми кулланылыштагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын тоту (алар янындагы территорияләрдәге үләннәрне чабып алу, ГСМ сатып алу, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү); бензокасилка өчен ягулык-майлау материаллары сатып алу;
4) җирле әһәмияттәге юлларны кышкы чорда кардан чистарту (ГСМ, трактор өчен запас частьләр сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);
4.1) Хәмитов урамы буенча вак таш өслек ремонтлауны, (эшләр һәм хезмәтләр өчен түләүне);
5) Татар Карамалы авылында халыкның күпләп ял итү урыннарын (Сабан туе территориясен) ремонтлау (эскәмияләр кую, флагшток урнаштыру, флагчыклардан гирлянда алу, территорияне төзекләндерү, төзелеш материаллары сатып алу, эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);

6) су башняларын, скважиналарны су белән тәэмин итү һәм су бүлеп бирү системаларын ремонтлау (су саклау зонасын төзекләндерү, төзелеш материаллары сатып алу, коймалар урнаштыру, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү)

3. Әлеге карарны Александровка авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Сарман муниципаль районының рәсми сайтында ( http:// sarmanovo. tatarstan.ru/), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 7 көн эчендә бастырып чыгарырга.

Сарман муниципаль районы
Александровка авыл җирлеге башлыгы
гражданнар җыенында рәислек итүче И.Ф.Вафин